Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Уразлы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“31” май 2021 ел № 28

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 4 пунктына « муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге башлыгы,
Уразлы авыл җирлеге Советы рәисе М.Г.Хәмидуллин